Кырык ел гомерен мәктәптә балаларга белем һәм тәрбия бирvгә багышлаган Ромодан районы Алтар авылы педагогы Рәхилә Таһир кызы Баляева турында сvзебез. Мин анын белән 1995 нче елнын май аенда, мәктәптә балалар Сабантуе vткәргәндә таныштым. Сезне дә, хөрмәтле “Юлдаш”ны укучыларыбыз, Рәхилә Таһир кызы Баляева белән таныштырам.

Рәхилә Таһир кызы Ромодан районы Алтар авылында 1945 елда туа. Жирле жиде еллык мәктәпне тәмамлагач, ул оч ел Кривозерье урта мәктәбендә укый һәм анда тулы урта белем турында аттестат ала. Аннары М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институтынын физика-математика факультетына укырга керә һәм дипломлы белгеч булып чыга. Шул вакытта ул Алтар авылында югары белем алган беренче хатын-кыз була. Белгеч буларак хезмәт биографиясен Ләмберә районынын Кривозерье урта мәктәбендә башлап жибәрә һәм анда ике ел укучыларга предметы буенча белем бирә. Ә инде 1968 елда туган мәктәбендә математика укытучысы булып эшли башлый. Мәктәп һәм балалар белән аралашу тормышынын аерылгысыз олеше булып китә. Бvген дә анын чыгарылыш сыйныф укучылары яраткан укытучыларын рәхмәт белән искә алалар.   Милли жанлы Рәхилә Таһир кызы Баляева эшләгәндә vзен талантлы, югары квалификацияле, vз фәнен белvче һәм яратучы педагог итеп кvрсәтә. 1969 елда ук аны мәктәп директорынын ун кулы - уку-тәрбия эше буенча урынбасары итеп билгелиләр. Бу вазифада ул 1993 елга кадәр эшли. Үз фәнен яратып укыту остенә, мәктәп тормышын тагын да жанландырып жибәрә: нинди генә бәйрәмнәр, конкурслар, кичәләр оештырмый ул! Ә 1993 елдан 2005 елга кадәр Рәхилә Таһир кызы туган авылы Алтар урта гомуми белем бирv мәктәбе коллективын житәкли. Озак вакыт мәктәпнен завучы, директоры булып эшләве дә очраклы тvгел. Ул бик жаваплы, сvзләрдә һәм эшләрдә конкрет педагог та, житәкче дә була. Мәктәптә унай, жылы эш атмосферасы тудыру, vзара анлашып эшләv, һәрбер укытучыга, укучыга ихтирамлы булу, аларны шәхес итеп кvрә белv – шул вакыттагы житәкченен эш алымы. Дәресләрне vткәрv технологиясен торлеләндерvне дә таләп итә, укучыларнын интеллектуаль vсешен булдыру остендә дә кvп эшли. Тарих-туган якны ойрәнv мәктәп музее да, 1995 елда, анын житәкчелегендә ачыла; ул хәзерге вакытта да унышлы эшләп килә.

Житәкчелек итv белән бергә, ул кvп вакытын ижтимагый эшләргә дә багышлый. Шулай, Рәхилә Таһир кызы Баляева 1981 елдан жирле хатын-кызлар Советы рәисе, 1985 елдан ул чыгарылыш сыйныф укучыларынын алтын медальгә эшләрне тикшерv буенча комиссия әгъзасы була, берничә тапкыр Алтар авыл Советы депутаты итеп сайлана. Ул Мордовия республикасы укытучыларынын IV съезды, 1991 елда Мордовия хатын-кызлары конференциясе делегаты була.

Үзенен тырыш педагогик эшчәнлеге очен Ряхилә Таһир кызы РСФСР мәгариф министрлыгынын һәм Мордовия мәгариф министрлыгынын Мактау грамоталары белән

бvләкләнә, vсеп килvче буынны укытуда һәм тәрбияләvдә аерым хезмәтләре очен ана “Олкән укытучы” исеме бирелә. Лаеклы ялда булган педагог бvген дә укучылары һәм укытучылары арасында зур абруй, хормәт иясе. Авылдашлары аны жаваплы, башлаган эшне ахырына кадәр башкаручан, таләпчән кеше буларак хормәт итә. Бу буш сvзләр генә тvгел, еллар дәвамында тырыш хезмәт белән исбатланган.
Рәхилә Таһир кызы Баляеванын эшен анын кызы Ләйлә Мянсур кызы Чапаева һәм килене Венера Абдулахать кызы Баляева дәвам итәләр. Алар Ромодан районы Алтар урта мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучылары булып эшлиләр. Киләчәктә укытучылар династиясе дәвам итәр дип уйлыйм. Гаиләдә кырык еллык педагогик стажлы әбиләренен, әниләренен эшен кvреп, укытучы хезмәтенә хормәт белән vскән балалар - Алтар мәктәбе коллективын тулыландырырлар дип уйларга урын бар.

Наилә НАСЫРОВА